МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

05.04.2019 Казан ш. № 21-75-59

“Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә һәм административ хокук бозулар турында эшләрне карап тикшерүгә вәкаләтле вазифаи затларның исемлеген һәм процессуаль документларның үрнәк формаларын раслау турында” 05.02.2015 ел, № 21-75-6 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

“Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында” 27 декабрь, 2018 ел, № 510-ФЗ Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, б о е р ы к б и р ә м:

“Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә һәм административ хокук бозулар турында эшләрне карап тикшерүгә вәкаләтле вазифаи затларның исемлеген һәм процессуаль документларның үрнәк формаларын раслау турында” 05.02.2015 ел, № 21-75-6 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгына (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 25.12.2015 ел, № 21-75-83, 19.01.2017 ел, № 21-75-12, 18.10.2017 ел, № 21-75-187 боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр нигезендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:

1.1 пунктчасының беренче абзацында “7.32.5 статьясының 1 өлеше” дигән сүзләрдән соң “7.32.6 статьясы,” дигән сүзләрне өстәргә;

1.2 пунктчасының беренче абзацында “7.32 статьясының 4,5,8 – 10 өлешләре,” дигән сүзләрдән соң “7.32.6 статьясы,” дигән сүзләрне өстәргә;

2 пунктның беренче абзацында “7.32.5 статьясының 1 өлеше,” дигән сүзләрдән соң “7.32.6 статьясы,” дигән сүзләрне өстәргә;

3 пунктның беренче абзацында 7.32 статьясының 8 – 10 өлешләре” дигән сүзләрдән соң “7.32.6 статьясы,” дигән сүзләрне өстәргә.

Министр вазифаларын башкаручы М.Д.Фәйзрахманов